| КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ |
|---|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2017 ел, 21 апрель № 234

г. Казань

Татарстан Республикасы яшьләр хөкүмәтен оештыру турында

Яшьләр сәясәтен тормышка ашыру, яшьләрне социаль-икътисадый бурычларны хәл итүгә җәлеп итү, яшь буынның кеше капиталын саклау, формалаштыру һәм туплау максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгының Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты каршында Татарстан Республикасы яшьләр хөкүмәтен оештыру турында тәкъдимен кабул итәргә.

2. Түбәндәге теркәлгәннәрне расларга:

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы яшьләр хөкүмәте багланышларын тәэмин итү буенча координация советы турында нигезләмә;

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы яшьләр хөкүмәте багланышларын тәэмин итү буенча координация советы составы.

3. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

F:\KARAR\2017\234.docx

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 21 апрель, 234 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы яшьләр хөкүмәте багланышларын тәэмин итү буенча координация советы турында нигезләмә

1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы яшьләр хөкүмәте багланышларын тәэмин итү буенча координация советы (алга таба – Координация советы) яшьләр сәясәтен тормышка ашыру, яшьләр инициативаларына булышлык күрсәтү һәм яшьләрне җәмгыятьнең фәнни-техник, социаль-икътисадый, сәяси һәм мәдәни тормышына җәлеп итү максатларында Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары багланышларны тәэмин итүче даими гамәлдә булган координация органы булып тора.

1.2. Координация советы үз эшчәнлеген Россия Федерациясе Конституциясе, федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, Татарстан Республикасы законнары, Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары, шулай ук әлеге Нигезләмә нигезендә гамәлгә ашыра.

2 Координация советының төп бурычлары

2.1. Координация советының төп бурычлары түбәндәгеләр:

Татарстан Республикасын үстерүнең фәнни, мәгариф, сәнәгать һәм аграр концепцияләренең үзара килешенгәнлегенә аерым игътибар биреп, Татарстан Республикасы өчен өстенлекле булган яшьләр сәясәте юнәлешләрен һәм яшь кадрлар әзерләү системасын саклау һәм үстерү өчен кирәкле шартлар тудыру;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр Татарстан Республикасының дәүләт яшьләр сәясәте стратегиясен раслау турында» 2016 ел, 4 февраль, 63 нче карары (алга таба – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 4 февраль, 63 нче карары) нигезендә дәүләт дәрәҗәсендә халыкара яшьләр хезмәттәшлеге мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы яшьләр хөкүмәте эшчәнлеген координацияләү;

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 ел, 4 февраль, 63 нче карары белән расланган 2030 елга кадәр Татарстан Республикасының дәүләт яшьләр сәясәте стратегиясен тормышка ашыруга булышлык күрсәтү;

Татарстан Республикасы яшьләр хөкүмәтенең учреждениеләр, фәнни, сәнәгать, мәдәни һәм башка мәнфәгатьле оешмалар белән эшчәнлеген координацияләү, шулай ук яшьләр сәясәтен тормышка ашыру максатларында аларның нәтиҗәле багланышларын тәэмин итү;

яшьләр кадрлары миграциясен киметүгә юнәлдерелгән чаралар эшләү, Татарстан Республикасы өчен традицион булган фәнни мәктәпләрне һәм юнәлешләрне саклау һәм үстерү;

Татарстан Республикасы яшьләр хөкүмәте эшчәнлеге кысаларында тормышка ашырыла торган конкурентлылыкка сәләтле яшьләр проектларын җайга салу һәм аларга ярдәм күрсәтү;

Татарстан Республикасы яшьләр хөкүмәте утырышларын оештыру һәм үткәрүдә ярдәм күрсәтү.

3. Структура һәм идарә итү

3.1. Координация советы составын Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты раслый.

3.2. Координация советы рәисе булып Татарстан Республикасы Премьер-министры тора, ул Координация советы белән гомуми идарә итүне гамәлгә ашыра. Агымдагы оештыру мәсьәләләрен хәл итүне Координация советы рәисе билгеләгән җаваплы секретарь гамәлгә ашыра.

3.3. Координация советы составына Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы яшьләр иҗтимагый оешмалары һәм Татарстан Республикасының югары белем бирүче мәгариф оешмалары җитәкчеләре һәм вәкилләре кертелә (килешү буенча).

4. Координация советы эшчәнлеген тәэмин итү

4.1. Координация советы утырышлары кимендә елга бер тапкыр үткәрелә. Утырышта Координация советы әгъзаларының өчтән бере катнашса, ул тулы хокуклы санала.

4.2. Утырышта фикер алышынган мәсьәләләр һәм Координация советы кабул иткән карарлар Координация советы әгъзаларының ачык тавыш бирүдәге гади күпчелек тавышы белән кабул ителә торган беркетмәләр белән рәсмиләштерелә. Тавышлар тигез булган очракта Координация советы рәисе тавышы хәлиткеч була. Координация советы рәисе карары белән карарлар Координация советы әгъзаларын язмача сораштыру юлы (читтән торып тавыш бирү) белән кабул ителә.

4.3. Координация советы утырышы йомгаклары буенча беркетмәләр утырыш үткәргән көннән соң 10 эш көне эчендә рәсмиләштерелә һәм Координация советы рәисе имза куйганнан соң өч көн эчендә Координация советының барлык әгъзаларына, мәнфәгатьле Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары, Татарстан Республикасы предприятиеләре һәм оешмалары, Татарстан Республикасы муниципаль районнары һәм шәһәр округлары башлыкларына җибәрелә.

4.4. Координация советы эшчәнлеген оештыру-техник һәм мәгълүмати-аналитик тәэмин итүне Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы гамәлгә ашыра.

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 21 апрель, 234 нче
карары белән расланды

Татарстан Республикасы башкарма хакимият органнары һәм Татарстан Республикасы яшьләр хөкүмәте багланышларын тәэмин итү буенча координация советы составы

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, Координация советы рәисе |
| Гафаров Шамил Хәмит улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты Җитәкчесе, Координация советы рәисе урынбасары |
| Леонов Владимир Александрович | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министры, Координация советы рәисе урынбасары |

Координация советы әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Габделганиев Фарит Солтан улы | Татарстан Республикасы экология һәм табигый байлыклар министры |
| Әхмәтов Марат Готыф улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры |
| Бәдретдинов Марс Сарыйм улы | Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Бариев Марат Мансур улы | Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасы депутаты, Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасының Физик культура, спорт, туризм һәм яшьләр эшләре комитеты әгъзасы (килешү буенча) |
| Белов Александр Николаевич | Татарстан Республикасы Президенты каршындагы Дәүләт хезмәте һәм кадрлар департаменты җитәкчесе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Беляков Роман Юрьевич | Татарстан Республикасы Президентының Эчке сәясәт мәсьәләләре департаменты җитәкчесе урынбасары – Гражданнар җәмгыяте институтлары белән үзара мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Вафин Адель Юныс улы | Татарстан Республикасы сәламәтлек саклау министры |
| Гайнетдинов Ренат Вәгыйз улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе башлыгы |
| Галиев Илдар Шамил улы | Татарстан Республикасында Террорга каршы комиссия аппараты җитәкчесе (килешү буенча) |
| Гарипов Илнур Мәхмүт улы | Татарстан Республикасы Президенты Аппараты Җитәкчесе урынбасары – Татарстан Республикасы Президентының Территорияләр белән эшләү идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Гарифуллин Рөстәм Марат улы | Татарстан Республикасы яшьләр эшләре һәм спорт министры урынбасары |
| Гафуров Илшат Рәфкат улы | «Казан (Идел буе) федераль университеты» югары белем бирүче федераль дәүләт автоном мәгариф учреждениесе ректоры, Татарстан Республикасы Югары уку йортлары ректорлары советы рәисе (килешү буенча) |
| Глухова Лариса Юрьевна | Татарстан Республикасы юстиция министры |
| Гревцов Андрей Борисович | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Хокук идарәсе башылгы |
| Зарипов Айрат Ринат улы | Республика «Татмедиа» басма һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе |
| Зарипова Эльмира Әмир кызы | Татарстан Республикасы хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министры |
| Здунов Артём Алексеевич | Татарстан Республикасы икътисад министры |

| | |
|---|---|
| Иванов Сергей Евгеньевич | Татарстан Республикасының Туристлык буенча дәүләт комитеты рәисе |
| Кәримов Альберт Әнвәр улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы сәнәгать һәм сәүдә министры |
| Миңнуллина Талия Илгиз кызы | Татарстан Республикасы Инвестицион үсеш агентлыгы җитәкчесе |
| Нәзиров Алмас Әмин улы | Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры |
| Петухов Андрей Юрьевич | «Кадрлар резервы» республика проекты башкарма директоры (килешү буенча) |
| Сафин Ленар Ринат улы | Татарстан Республикасы транспорт һәм юл хуҗалыгы министры |
| Сибагатуллин Айрат Миңнемулла улы | Татарстан Республикасы мәдәният министры |
| Фәйзуллин Ирек Әнвәр улы | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министры |
| Фаттахов Энгель Нәвап улы | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министры |
| Хәбибуллин Рафис Җәүдәт улы | Татарстан Республикасы гражданнар оборонасы эшләре һәм гадәттән тыш хәлләр министры |
| Хамаев Азат Кыям улы | Татарстан Республикасы җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министры |
| Шәйхетдинов Роман Александрович | Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – Татарстан Республикасы мәгълүматлаштыру һәм элемтә министры |
| Шакирова Гузәл Рәис кызы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсе башлыгы |
| Шакиров Минсәгыйть Закир улы | Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре советы рәисе (килешү буенча) |

| | |
|---|---|
| Шихобалов Валентин Викторович | «Татарстан Республикасының иҗади яшьләре академиясе» төбәк иҗтимагый оешмасы президенты (килешү буенча). |

F:\KARAR\2017\234-2.docx